ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2020 Казан ш. № 585-43/тко-2020

Татарстан Республикасы территориясендә Көнчыгыш эшчәнлек зонасында «Гринта» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторы хезмәтенә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2019 №11-54/тко карары белән расланган озак сроклы чик дәрәҗәдә бердәм тарифларга 2021 ел өчен үзгәреш кертү хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя кую турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2021 елга каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторы хезмәтләренә озак сроклы чик дәрәҗә бердәм тарифларга үзгәреш кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2020-2022 елларга Татарстан Республикасы территориясендә Көнчыгыш эшчәнлек зонасында «Гринта» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторы хезмәтенә чик дәрәҗә бердәм тарифлар билгеләү турында» 19.12.2019 № 11-54/тко карары кушымтасына үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә (кушымтада бирелә) бәян итәргә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л. Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
19.12.2019 № 11-54/тко
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасының Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2020 № 585-43/тко-2020
карары редакциясендә)

# Татарстан Республикасы территориясендә Көнчыгыш эшчәнлек зонасында «Гринта» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторы хезмәтенә 2020-2022 елларга чик дәрәҗәдә бердәм тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифлар, сум/куб.метр | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 ел | | 2021 ел | | 2022 ел | |
| | | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| | «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | | | | |
| 1 | «Гринта» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | | | | | | |
| 1.1 | халык (тарифлар НДС белән күрсәтелгән)** | 439,03 | 456,62 | 456,62 | 488,59 | 488,59 | 501,3 |
| 1.2 | башка кулланучылар (тарифлар НДС исәбеннән башка күрсәтелгән) | 365,86 | 380,52 | 380,52 | 407,16 | 407,16 | 417,75 |

<*> «Гринта» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте 2021-2022 елларда Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2020 елның 20 октябрендәге 174/о номерлы боерыгы белән расланган инвестицион программаны тормышка ашырачак. 2021 елга 1 куб.м. каты коммуналь калдыкларга туры килгән инвестицияләр күләме, НДС ны исәпкә алмыйча, 81,30 сум тәшкил итә.
<**> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге